КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 декабрь г.Казань № 1205

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыру турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1099 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 17 декабрь, 1157 нче; 2021 ел, 19 февраль, 88 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2020 – 2021 елларда» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү буенча «Яңа туган балага бүләк» акциясен тормышка ашыруга бәйле чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә (алга таба – Тәртип):

1.3 пунктның беренче абзацында «катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар» сүзләрен «катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан җибәрелгән» сүзләренә алмаштырырга;

2.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү срокларын, заявкалар бирелә башлау яки кабул итү тәмамлану датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

тугызынчы абзацта «һәм бәяләү» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.2 пунктның беренче абзацында «заявкаларны кабул итү срогы башлану планлаштырылган» сүзләрен «заявкалар кабул ителә башлаган» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Сайлап алуда катнашу өчен коммерциягә карамаган оешмалар Вәкаләтле органга түбәндәгеләрне тапшыра:

бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма буенча тиешле чыгымнар күләменең нигезләүләре белән субсидия күләменең исәп-хисабын теркәп, яңа туган балалы гаиләләрне бу Тәртипнең 3.12 пункты нигезендә билгеләнә торган субсидия бирү нәтиҗәсенә ярашлы санда бүләк комплектлары белән тәэмин итү турында коммерциягә карамаган оешма йөкләмәсе булган заявка;

гамәлгә кую документларының, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы документларның коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе кул куйган һәм мөһер белән таныкланган күчермәләрен;

коммериягә карамаган оешманың мөһере белән таныкланган оешманы дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан язу кәгазе күчермәсен;

коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе кул куйган һәм мөһер белән таныкланган коммерциягә карамаган оешманың штат расписаниесе күчермәсен;

һәр социаль әһәмиятле чарада катнашучылар санын күрсәтеп, соңгы өч елга коммерциягә карамаган оешма эшчәнлеге турында, шул исәптән балалары булган аз керемле гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән, гамәлгә ашырыла торган социаль әһәмиятле проектлар турындагы мәгълүматны;

Татарстан Республикасы территориясендә заявка бирелә торган елга кадәрге елда яңа туган балалы гаиләләрне бүләк комплектлары белән тәэмин итү эшчәнлеген гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматны;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан заявкалар кабул ителә башланганга кадәр өч айдан да иртәрәк бирелмәгән коммерциягә карамаган оешма турында мәгълүмат белән өземтә күчермәсен;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча заявкалар кабул ителә башлый торган айга кадәрге айның беренче көне хәленә карата салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органы биргән белешмә кәгазен;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы каршында үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау турында коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) кул куйган, мөһер сугылган белешмә кәгазе;

коммерциягә карамаган оешманың үзгәртеп оештыру процессында булмавын (башка юридик затның коммерциягә карамаган оешмасына кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерелмәвен, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәвен, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавынраслый торган, коммерциягә карамаган оешманың җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) кул куйган һәм мөһер сугылган белешмә кәгазен;

коммерциягә карамаган оешманың чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында теркәлү урыны булып Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләре (офшор зоналар) үткәрелгәндә мәгълүмат ачу һәм бирү каралмаган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория торган чит ил юридик затлары катнашу өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе кул куйган һәм коммерциягә карамаган оешманың мөһере сугылган белешмә кәгазен;

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә субсидия бирү каралган елда Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмавын раслый торган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) кул куйган, мөһер сугылган белешмә кәгазен;

яңа туган балалы гаиләләрне бүләк комплектлары белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага кирәкле эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә өченче затлар белән төзелгән, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе кул куйган һәм мөһер белән таныкланган шартнамәләр күчермәләрен.

Коммериягә карамаган оешманың Вәкаләтле орган тарафыннан бердәм порталда һәм Вәкаләтле органның рәсми сайтында заявка турында һәм сайлап алуда катнашуга бәйле коммерциягә кармаган оешма турында мәгълүмат һәм сайлап алуда катнашуга бәйле коммерциягә кармаган оешма турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгы заявкада күрсәтелә.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп брошюровкаланган, һәр бите номерланган, коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең үз кулы белән имзасы куелган һәм мөһер белән таныкланган булырга тиеш.

Коммерциягә карамаган оешмалар бер генә заявка бирергә мөмкин.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең үз кулы белән куелган имзасы белән расланган һәм мөһер сугылган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Заявкалар кабул итү срогы башланганга кадәр яки заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң Вәкаләтле органга (шул исәптән почта элемтәсе оешмалары аша) кергән заявкалар теркәлми, карап тикшерелми (шул исәптән алга таба сайлап алуларны үткәргәндә), бу турыда Вәкаләтле орган коммерциягә карамаган оешмага заявка кергән көннән 10 эш көне эчендә электрон почта аша хәбәр итә һәм заявкаларны аңа почта элемтәсе оешмасы аша кире кайтара.

Яраклы дип танылган заявкалар кире кайтарылмый һәм Вәкаләтле органда саклана.»;

2.6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Заявкаларны карап тикшерү максатларында Вәкаләтле орган тарафыннан заявкаларны карап тикшерү комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә.»;

икенче абзацта «һәм Вәкаләтле орган каршындагы иҗтимагый советлар вәкилләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявканың (заявкаларның) һәм коммерциягә карамаган оешманың (оешмаларның) бу Тәртипнең 1.5, 2.2 һәм 2.3 пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры килүе яки заявканы (заявкаларны) кабул итүдән баш тарту турында карар (алга таба – Комиссия карары) кабул итә.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы (заявкаларны) кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

заявка биргән коммерциягә карамаган оешма бу Тәртипнең 1.5 һәм 2.2 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килми;

бирелгән заявка һәм аңа теркәлә торган документлар сайлап алу үткәрелү турында белдерүдә билгеләнгән заявкаларга һәм документларга карата таләпләргә туры килми, шулай ук коммерциягә карамаган оешманың урнашу урыны һәм адресы турында дөрес булмаган белешмәләр, шул исәптән мәгълүмат булу;

заявка аларны бирү (шул исәптән почта элемтәсе оешмалары аша бирү) өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң керү;

заявкада күрсәтелгән финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешенең һәм бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләренә туры килә торган күләмне нигезләүләр белән субсидия күләме исәп-хисапларының туры килмәве.

Комиссия карары Комиссия тарафыннан карар кабул ителгән көннән өч эш көненнән дә артмаган срокта заявкаларны карап тикшерү турында беркетмә белән рәсмиләштерелә. Комиссиянең заявкаларны карап тикшерү турындагы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны

үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

коммерциягә карамаган оешмага (оешмаларга) бирелә торган субсидия (субсидияләр) күләме (күләмнәре).»;

2.8 һәм 2.9 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

2.10 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Коммерциягә карамаган оешманың субсидия күләмен ($P_{суб}$) билгеләү Комиссия тарафыннан заявкага бирелгән теркәлү номеры нигезендә түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:»;

тугызынчы абзацта «4 560 берәмлек тәшкил итә» сүзләрен «2020 елда – 4 415 берәмлек, 2021 елда – 4 560 берәмлек, 2022 елда 4 365 берәмлек тәшкил итә» сүзләренә алмаштырырга;

2.11 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

2.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Комиссиянең заявкаларны карап тикшерү турындагы беркетмәсе нигезендә Вәкаләтле орган, Комиссиянең заявкаларны карап тикшерү турындагы беркетмәсе төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көннән дә соңга калмыйча, сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) билгели, субсидия бирү турында карар кабул итә һәм бердәм порталда һәм Вәкаләтле органның рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала торган сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килмәвен билгели торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

Субсидия бирү турында килешү (килешүләр) төзелә торган субсидия алучы (алучылар) исеме (исемнәре) һәм аңа (аларга) бирелә торган субсидия күләме (күләмнәре).»;

3.1 – 3.4 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

3.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия бирү турындагы килешүгә үзгәрешләр кертү яклар килешүе буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең (шартнамәнең) бертип формасына кушымтада бирелгән форма буенча субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла (кирәк булганда). Субсидия бирү турындагы килешүне өзү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең (шартнамәнең) бертип формасына кушымтада бирелгән форма буенча Субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән рәсмиләштерелә (кирәк булганда).»;

3.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3.7 пунктта «коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән» сүзләрен «сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән» сүзләренә алмаштырырга;

3.8 пунктта:

беренче абзацта «Коммерциягә карамаган оешма» һәм «әзерли» сүзләрен «Сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр)» һәм «кул куя» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Сайлап алуда җиңүченең (җиңүчеләрнең) электрон почтасы адресына Субсидия бирү турында килешү проекты (проектлары) килү хакында Вәкаләтле органның электрон почтасы адресына хәбәрнамә кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә сайлап алуда катнашучы (катнашучылар) тарафыннан аның (алар) ягыннан кул куелган Субсидия бирү турында килешү (килешүләр) Вәкаләтле органга тапшырылмаган булса, сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) Субсидия бирү турында килешү (килешүләр) төзүдән читләшкән дип санала.»;

3.9 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуда җиңүченең (җиңүчеләрнең) субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә һәм субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләргә ирешү буенча йөкләмәсе, аларга ирешмәгән өчен җаваплылык;»;

бишенче абзацта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Вәкаләтле орган тарафыннан субсидиянең калган өлешен файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, субсидия алучы (алучылар) тарафыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шартлар;»;

3.11 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия алучы (алучылар), шулай ук субсидия алучы (алучылар) белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алу тыела.»;

3.12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.12. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – агымдагы елның 31 декабре хәленә карата яңа туган балалы гаиләләрне тәэмин итү өчен субсидия алучы (алучылар) тарафыннан Татарстан Республикасы медицина оешмаларына бүләк комплектларын (2020 елда – 4 415 берәмлек, 2021 елда – 4 560 берәмлек, 2022 елда – 4 365 берәмлек) илтеп бирү.

Субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешүне бәяләү ($П_Р$) Вәкаләтле орган тарафыннан түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$П_р = \frac{КП_{факт}}{КП_{план}} \times 100\%,$$

монда:

$КП_{факт}$ – яңа туган балалы гаиләләрне тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы медицина оешмаларына фактта илтеп бирелгән бүләк комплектлары саны;

$КП_{план}$ – агымдагы елда яңа туган балалы гаиләләрне тәэмин итү өчен бүләк комплектларының план саны.»;

3.13 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Субсидия алучы Вәкаләтле органга Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләгән килешүләрнең (шартнамәләрнең) бертип формаларында билгеләнгән формалар буенча түбәндәгеләрне тапшыра:

финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында арта бара торган йомгак белән формалаштырыла торган хисап – квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 15 эш көненнән дә соңга калмыйча;

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап – ел саен, әмма хисап елыннан соң килә торган елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча.»;

5 бүлекнең исемендә «Контрольдә тотуны» сүзләрен «Контрольдә тотуны (мониторингны)» сүзләренә алмаштырырга;

5.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау Вәкаләтле орган һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.»;

5.3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап һәм субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшырылмаган, хисаплар тапшыру сроклары бозылган очракта – тулы күләмдә;»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше булганда, субсидия алучы (алучылар) Вәкаләтле органга хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр әлеге акчага ихтыяҗ булуны нигезли торган документларны тапшыра.

Вәкаләтле орган субсидия алучыдан (алучылардан) әлеге документларны алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 15 көн эчендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, субсидия алучының (алучыларның) әлеге акчага ихтыяҗы булу турында яки аларга ихтыяҗ булмаганда әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтару хакында карар кабул итә.

Вәкаләтле органның хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә субсидия алучының (алучыларның) ихтыяҗы булу турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән карары булмаган очракта, субсидия алучы (алучылар) хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр

әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарырга тиеш.

Вәкаләтле орган тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешенә субсидия алучының (алучыларның) ихтыяҗы булу турында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелгән карары булган очракта, субсидия алучы (алучылар) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып әлеге акча торган чыгымнарны бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатларга тотарга хокуклы.»;

5.6 пунктта «контрольдә тоту» сүзен «контрольдә тоту (мониторинглау)» сүзләренә алмаштырырга;

Тәртипнең 1 нче кушымтасы башисемендә «1 нче кушымта» сүзләрен «кушымта» сүзенә алмаштырырга;

бу Тәртипнең 2 нче кушымтасы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында халыкның җан башына билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итүне оештыру мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламентында:

1.2 пунктның бишенче абзацында «һәм муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.1.3 пунктта «, шул исәптән элемтәгә керү телефоннарын күрсәтеп, Татарстан Республикасы медицина оешмаларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Агымдагы елның гыйнварыннан Субсидия бирү турында килешү төзелә торган айга кадәр (айны кертеп) Татарстан Республикасы медицина оешмаларының бүләк комплектларына кирәкле күләмдә ихтыяҗын тәэмин итү өчен заявка Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан субсидия алучы турында мәгълүмат алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә бирелә.»;

3.5 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу Регламентның 3.3 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән очракта, субсидия алучы бүләк комплектларын Татарстан Республикасы медицина оешмаларына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы заявкасында күрсәтелгән срокта алып килеп бирүне гамәлгә ашыра.»;

3.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Татарстан Республикасы медицина оешмалары бүләк комплектлары калган очракта:

хисап елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яңа туган балалы гаиләләргә балалар кирәк-яракларының бүләк комплектларын бирү турында» 2019 ел, 4 декабрь, 1100 нчы карары белән расланган Яңа туган балалы гаиләләрне балалар кирәк-яракларының бүләк комплектлары белән тәэмин итү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, аларны хисап финанс елында яңа туган балалы гаиләләргә бирә;

хисап елыннан соң килә торган елның 1 июле хәленә карата – аларны кабул итү-тапшыру акты нигезендә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән килештереп, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы боерыгына таянып, хисап елыннан соң килә торган елның 1 августына кадәр «Республика махсуслаштырылган бала йорты» дәүләт казна сәламәтлек саклау учреждениесенә тапшыра.

Татарстан Республикасы медицина оешмалары җитәкчеләре ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 10ысыннан да соңга калмыйча, яңа туган балалы гаиләләргә бүләк комплектлары бирү исемлекләренең расланган күчермәләрен теркәп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына үткән айда тапшырылган бүләк комплектлары турында хисап бирә.

Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан бүләк комплектлары бирү тәртибенең үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

бу карар (әлеге карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының туксанынчы һәм туксан беренче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә;

бу карарның 1 пунктындагы йөз тугызынчы – йөз ундүртенче абзацларының гамәле 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин